**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО**
**РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 13.07.2020** **№ 545**

## Биектау муниципаль районы муниципаль милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында

2020 елның 1 апрелендәге 98-ФЗ номерлы «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 439 номерлы «Күчемсез милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартларына һәм срокларына таләпләр билгеләү турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 314 нче номерлы ««Татарстан Республикасы дәүләт милкендәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп тору шартлары турында» карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 22 апрелендәге 820-р номерлы күрсәтмәсе нигезендә, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектереп торуның түбәндә китерелгән шартларын расларга.
2. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында: http://pravo.tatarstan.ru веб - адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Биектау муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ рәисе С.М. Минһаҗевка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

Расланды
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2020 елның 13.07.2020
№545 карары белән

**Муниципаль милектәге күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвен кичектерү шартлары**

1. Күчемсез мөлкәттән файдаланган өчен 2020 елда каралган аренда түләвен кичектерүнең әлеге шартлары Татарстан Республикасы Президентының 2020 елда «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законның 11 статьясы нигезендә, яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәлнең начараюы шартларында иң күп дәрәҗәдә зыян күргән, Татарстан Республикасы территориясендә Россия икътисады тармакларында эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр булып торган арендаторлар белән Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү турында карар кабул итүгә кадәр төзелгән күчемсез мөлкәтне арендалау шартнамәләренә карата кулланыла, аларның исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган (алга таба - аренда килешүе, кичектереп тору).

2. Күчемсез милеккә карата, торак урыннардан тыш, кичектерү бирелә.

3. Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимын кертү датасыннан башлап 2020 елның 1 октябренә кадәр түбәндәге шартларда кичектерү бирелә:

а) аренда түләве буенча бурыч түләүгә 2021 елның 1 январеннан да иртәрәк булмаган һәм 2023 елның 1 январеннан да соңга калмыйча, этаплап, айга бер тапкырдан ешрак булмаган, күләме аренда шартнамәсе буенча ай саен аренда түләвенең яртысыннан артмаган тигез түләүләргә туры килергә тиеш;

б) кичектерү Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимының гамәлдә булу срогына тиешле чор өчен аренда түләве күләмендә һәм 2020 елның 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булу туктатылган көннән алып тиешле чор өчен аренда түләвенең 50 проценты күләмендә бирелә;

в) арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәү өчен штрафлар, чит акчалардан файдаланган өчен процентлар яисә башка җаваплылык чаралары (шул исәптән, мондый чаралар аренда шартнамәсендә каралган очракларда) кичектереп тору белән бәйле рәвештә кулланылмый;

г) кичектерү бирелүгә бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләрне арендага бирүче тарафыннан билгеләү рөхсәт ителми;

д) кичектерү бирелә торган аренда түләве күләме яклар килешүе буенча киметелергә мөмкин;

е) әгәр аренда шартнамәсендә арендатор тарафыннан коммуналь хезмәт күрсәтүләр һәм (яисә) арендага бирелә торган мөлкәтне карап тотуга чыгымнарны файдаланган өчен түләүләрне аренда түләвенә кертү каралган булса, аренда

түләвенең күрсәтелгән өлеше буенча кичектерү бирелми, моңа Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы гамәлдә булган чорда арендага бирүче мондый хезмәтләр өчен түләүдән һәм (яисә) мондый чыгымнарны түләүдән азат итәлә торган очраклар керми.

4. 3 пунктта каралган кичектерү шартлары мондый килешүне төзү датасына бәйсез рәвештә кичектерү турында аренда шартнамәсенә өстәмә килешүләргә карата кулланыла.